МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.04.2015 г. Казань № 5261/15

**«Илһам» бөтенроссия яшь язучылар бәйгесенең нәтиҗәләре турында**

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә карата кызыксыну уяту, әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне ачыклау, яшь язучыларны таныту максатыннан, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасы Язучылар союзы белән берлектә 2015 елның 15 нче апрелендә татар телендә иҗат итүче мәктәп укучылары арасында «Илһам» бөтенроссия яшь язучылар, шагыйрьләр һәм драматурглар бәйгесе (алга таба – Бәйге) уздырылды. Бәйгегә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләреннән һәм Россия Федерациясе төбәкләреннән 622 эш кабул ителде. I тур нәтиҗәләре буенча эксперт комиссиясе тарафыннан өч номинациягә караган 297 эш сайлап алынды.

Оештыру комитеты һәм жюри биргән материаллардан чыгып, б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының дипломын һәм истәлекле бүләген Гран-при иясе дип танылган түбәндәге укучыга тапшырырга:

Аксубай муниципаль районы М.И. Габдрахманов исемендәге Яңа Ибрай урта гомуми белем мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы Әмирова Рузиләгә.

2. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының I дәрәҗәле дипломын һәм премияне түбәндәге укучыларга тапшырырга:

*Шигърият номинациясе*

Буа муниципаль районы М.М. Вахитов исемендәге гимназиясенең 7 нче сыйныф укучысы Галимова Назлыгөлгә;

Теләче муниципаль районы Баландыш төп гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Тимербайев Илсафка;

Казан шәһәре 1 нче татар гимназиясенең 11 нче сыйныф укучысы Фасахов Булатка;

*Чәчмә әсәрләр номинациясе*

Арча муниципаль районы Носы төп гомуми белем бирү мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы Романова Алиягә;

Мөслим муниципаль районы гимназиясенең 8 нче сыйныф укучысы Кашапова Илүзәгә;

Казан шәһәре 1 нче татар гимназиясенең 10 нче сыйныф укучысы Җамалиев Ниязга;

*Драматургия номинациясе*

Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый төп гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Нәбиуллина Фирүзәгә;

Актаныш муниципаль районы Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатының 11 нче сыйныф укучысы Галиева Алинәгә.

3. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының II дәрәҗәле дипломын һәм премияне түбәндәге укучыларга тапшырырга:

*Шигърият номинациясе*

Казан шәһәре 111нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныф укучысы Әхмәтҗанова Энҗегә;

Казан шәһәре 80 нче мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Галимова Иринага;

Актаныш муниципаль районы Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатының 11 нче сыйныф укучысы Фәррахова Риммага;

*Чәчмә әсәрләр номинациясе*

Башкортстан РеспубликасыИске Балтач 1нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныф укучысы Хәмәтханова Дианага;

Актаныш муниципаль районы Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия – интернатының 9 нчы сыйныф укучысы Салахова Айсинәгә;

Мөслим муниципаль районы Гимназиясенең 10 нчы сыйныф укучысы Сәрвәрова Нәзиләгә;

*Драматургия номинациясе*

Лаеш муниципаль районы Кече Елга гомуми урта белем мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Галиуллина Энҗегә;

Чирмешән муниципаль районы Лашман урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы Галимова Алсинәгә.

4. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының III дәрәҗәле дипломын һәм премияне түбәндәге укучыларга тапшырырга:

*Шигърият номинациясе*

Самара өлкәсе Яктылык мәктәбенең 5 нче сыйныф укучысы Абдерахимова Алсуга;

Казан шәһәре Татар телендә белем бирүче 27 нче гимназиясенең 9 нчы сыйныф укучысы Нурмиева Энҗегә;

Яр Чаллы шәһәре М.Вахитов исемендәге 2 нче гимназиясенең 11 нче сыйныф укучысы Дәүлиева Язгөлгә;

*Чәчмә әсәрләр номинациясе*

Яңа Чишмә муниципаль районыЗирекле лицееның 6 нчы сыйныф укучысы Зарипова Әлфинәгә;

Теләче муниципаль районы Алан урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Хәбирова Динәгә;

Сарман муниципаль районы Гимназиясенең 10 нчы сыйныф укучысы Ханова Эльвинага;

*Драматургия номинациясе*

Яр Чаллы шәһәре 34 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныф укучысы Хәйруллина Айсылуга;

Башкортстан Республикасы Иске Балтач икенче урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы Хәйртдинова Гүзәлгә.

5.Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының дипломын һәм кызыксындыру бүләген (акчалата премия) түбәндәге укучыларга тапшырырга:

Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе гомуми белем бирү мәктәбенең 4 нче сыйныф укучысы Шакиров Илнарга;

Яшел Үзән муниципаль районы 3 нче гимназиясенең 2 нче сыйныф укучысы Дәүләтшина Раянәгә;

Башкортстан Республикасы Татар гимназиясенең 4 нче сыйныф укучысы Хәбибрахманов Уралга;

Түбән Кама муниципаль районы 7 нче гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныф укучысы Шәфигуллина Айсылуга;

Зәй муниципаль районы 6 нчы белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныф укучысы Нәбиуллин Рушатка;

Минзәлә муниципаль районы Гимназиясенең 2 нче сыйныф укучысы Галиева Эльвинага;

Балтач муниципаль районы Яңгул гомуми урта белем бирү мәктәбенең 4 нче сыйныф укучысы Сәләхетдинова Эльвирага;

Яр Чаллы шәһәре 1 нче урта белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныф укучысы Шәфикова Алинәгә;

Казан шәһәре 1 нче гимназия 4 нче сыйныф укучысы Миңнегарипов Рәдифкә;

Яр Чаллы шәһәре 50 нче гомуми урта белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныф укучысы Тимергалиева Аделинага.

6. Бәйгене тиешле дәрәҗәдә үткәрүдә шартлар тудырган өчен Казан шәһәре мәгариф идарәсе башлыгы Илсур Гәрәй улы Һадиуллинга, Казан шәһәре 2 нче лицей-интернаты директоры Ирек Асаф улы Ризвановка һәм лицейның педагогик коллективына Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының рәхмәтен белдерергә.

7. Боерыкны мәгариф бүлекләренә һәм идарәләренә җиткерергә.

8. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары-министр** **Э. Н. Фәттахов**